ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы

422756, ТР Әтнә муниципаль районы,
Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8
тел. 34-6-25

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Большеменгерского сельского поселения
Атнинского муниципального района

422756, РТ, Атнинский муниципальный район,
село Большой Менгер, улица Советская, 8
тел. 34-6-25

**КАРАР № 123**

**Олы Мәңгәр авылы** **«29» июль 2025 ел**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге 108 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 397 статьясы, 2025 елның 17 июнендәге 02-08-02-2025 номерлы прокурор протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге 108 номерлы «Җир салымы турында» карарына (20.01.2020 ел № 125, 30.10.2020 ел № 9, 30.01.2024 ел № 90, 24.10.2024 ел №102 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.Карарның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4.3 пунктчасы өстәргә:**
“4.3. Оешмалар-салым түләүчеләр салымны узган салым чорыннан соң килүче елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча түләргә тиеш. Салым буенча аванс түләүләре оешмалар-салым түләүчеләр тарафыннан узган хисап чорыннан соң килүче айның 28 числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Олы Мәңгәр авыл җирлеге
башлыгы Филатова Ф.Ф.